ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.03.2022 № 245

Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларын кызыксындыру (бүләкләү) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга муниципаль районының билгеләнгән нормаларны, таләпләрне үтәгән иң яхшы спортчыларына: Атказанган спорт мастеры, халыкара класслы спорт мастеры, спорт мастеры, спорт мастеры кандидаты, беренче өлкәннәр разрядын бирү өчен адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләү турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү критерийларын расларга (2 нче кушымта).

3. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендияләрен финанслауны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанслау чаралары исәбеннән карауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.03.2022 № 245

карарына 1 нче кушымта

**Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләү турында Нигезләмә**

1. Алабуга муниципаль районының билгеләнгән нормаларны, таләпләрне үтәгән иң яхшы спортчыларына:
   Атказанган спорт мастеры, халыкара класслы спорт мастеры, спорт мастеры, спорт мастеры кандидаты, беренче өлкәннәр разрядын бирү өчен адреслы ярдәм күрсәтү, кызыксындыру (алга таба - текст буенча - бүләкләү).
2. Бүләкләү түбәндәге спорт разрядларын биргәндә гамәлгә ашырыла: «Атказанган спорт мастеры», «Халыкара класслы спорт мастеры», «Россия спорт мастеры», «Спорт мастеры кандидаты», «1 өлкән разряд».
3. Бүләкләү, әлеге Нигезләмәнең 7 п. күрсәтелгән документлар тапшырылганнан соң, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанслау чаралары исәбеннән, 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, бер генә тапкыр гамәлгә ашырыла.
4. Бүләкләүләрне раслауга кандидатлар исемлеге Алабуга муниципаль районы спорт мәктәпләренең * тәкъдиме буенча төзелә.
5. Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен критерийлар әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына теркәлгән.
6. Бер генә тапкыр бирелә торган түләүне алуга кандидатлар булып, Алабуга муниципаль районының спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр тора ала.
7. Бер генә тапкыр бирелә торган түләүне алу өчен кандидатлар, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторына, түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:
   - Алабуга муниципаль районы спортчысын бүләкләүгә дәгъва кылу турында белешмәләр (әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта);
   - спорт исемен бирү турында Россия Федерациясе,Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгының күчермәсе;
   - паспорт күчермәсе;
   - Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсен (ИНН);
   - индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган һәм индивидуаль счет иминият номеры турында белешмәләр булган документның күчермәсе;

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Алабуга муниципаль районы спорт мәктәбе директоры (җитәкчесе) тәкъдим итүне (үтенечнамәне) әзерли һәм имзалый.

Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләү турында Нигезләмәсеә 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы спортчыларына бүләкләү билгеләүгә дәгъва кылучы турында белешмәләр**

| Дәгъвачының ФИА.и. | Туган көне (числосы, ае, елы) | Адрес | Спорт мәктәбенең атамасы | Спорт разрядын бирү турында мәгълүмат (разряд, бирү датасы) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Өстәмә белем бирү учреждениесе директоры_______________________(ФИА.и.)
(имза)
МУ

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
141.03.2022 № 245

карарына 2 нче кушымта

**Спорт разрядларын бирү өчен билгеләнгән нормаларны һәм таләпләрне үтәгән Алабуга муниципаль районы спортчыларына бер генә тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү критерийлары**

| № | Бирелгән спорт разрядының исеме | Бүләкләү күләме, мең сум |
|---|---|---|
| 1. | Атказанган спорт мастеры | 25 000, 00 |
| 2. | Халыкара класслы спорт мастеры | 20 000, 00 |
| 3. | Россия спорт мастеры | 15 000, 00 |
| 4. | Спорт мастерына кандидат | 10 000, 00 |
| 5. | 1 өлкәннәр разряды | 5 000, 00 |